КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 июль г.Казань № 670

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының хезмәт таныклыгы турында» 2007 ел, 13 август, 385 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының хезмәт таныклыгы формасы һәм аны тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының хезмәт таныклыгы турында» 2007 ел, 13 август, 385 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 ноябрь, 962 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының хезмәт таныклыгы формасы һәм аны тапшыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) таныклыкның эчке сул һәм уң яклары:

Министерство лесного хозяйства
Республики Татарстан

УДОСТОВЕРЕНИЕ N ______

(фамилия)

(имя)

(отчество (при наличии))

Дата выдачи "__" ________ 20_ г.

Министр – Главный
государственный лесной инспектор
Республики Татарстан ____________ ____________
подпись (фамилия, инициалы)

(должность)

(должность государственного инспектора)

При исполнении полномочий имеет право осуществлять федеральный государственный лесной контроль (надзор), лесную охрану на землях лесного фонда в пределах своей компетенции.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Таныклыкның тасвирламасы:

таныклык бөкләнгән килеш 105 х 65 миллиметр һәм ачык килеш 210 х 65 миллиметр зурлыгында булган кара кызыл төстәге күн яки ледерин тышлыклы китапчыктан гыйбарәт.

Таныклык тышлыгының тышкы ягында урта өлешендә – бронза фольгадан 30 миллиметр диаметрлы Татарстан Республикасы Дәүләт гербы рәсеме төшерелә, аның өстендә – ике юлга Times New Roman шрифтының 16 нчы размерлы ярым калын юл хәрефләре белән рус телендә «Министерство лесного хозяйства Республики Татарстан» дип, аның астында ике юлга Times New Roman шрифтының 6 нчы размерлы ярым калын юл хәрефләре белән рус телендә «Государственный лесной инспектор Республики Татарстан» дип языла.

Таныклыкның эчке сул һәм уң якларында (ачык килеш) 90 х 60 миллиметр зурлыгындагы алсу тангирлы челтәр фонында текст язылган махсус кәгазь бланкы ябыштырыла.

Таныклык тышлыгының эчке сул ягындагы махсус кәгазьдә рус телендә түбәндәге текст язылырга тиеш:

өстән уңда һәм уртада – ике юлга Times New Roman шрифтының 10 нчы размерлы ярым калын юл хәрефләре белән эшләнгән «Министерство лесного хозяйства Республики Татарстан» дигән язу;

махсус кәгазьнең вертикаль ягындагы кырыеннан 5 миллиметр калдырып түбәнрәк сулда һәм уртада – Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының 30 х 25 миллиметр зурлыгында төсле фотосурәте;

фотосурәттән уңда һәм уртада:

«УДОСТОВЕРЕНИЕ» дигән язу һәм Times New Roman шрифтының 11 нче размерлы ярым калын баш хәрефләр белән эшләнгән таныклык номеры;

түбәнрәк – өч юлга Times New Roman шрифтының 11 нче размерлы ярым калын баш хәрефләр белән эшләнгән Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

түбәнрәк сулда – Times New Roman шрифтының 8 нче размерлы ярым калын юл хәрефләре белән эшләнгән «Дата выдачи «___» _______ 20___ г.» дигән язу;

түбәнрәк сулда – Times New Roman шрифтының 8 нче размерлы юл хәрефләре белән эшләнгән вазифа атамасы, уңда – таныклыкка кул куючы Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының инициаллары һәм фамилиясе.

Таныклык тышлыгының эчке уң ягындагы махсус кәгазьдә рус телендә түбәндәге текст язылырга тиеш:

Times New Roman шрифтының 11 нче размерлы ярым калын баш хәрефләр белән эшләнгән «должность» дигән язу, вазифа Министрлыкның яки ведомство буйсынуындагы казна учреждениесенең оештыру структурасы нигезендә күрсәтелә;

түбәнрәк уртада – Times New Roman шрифтының 11 нче размерлы ярым калын баш хәрефләр белән эшләнгән «должность государственного инспектора» дигән язу;

түбәнрәк сулда – рус телендә түбәндәге текст:

Times New Roman шрифтының 10 нчы размерлы ярым калын юл хәрефләре белән эшләнгән «При исполнении полномочий имеет право осуществлять федераль-

ный государственный лесной контроль (надзор), лесную охрану на землях лесного фонда в пределах своей компетенции.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Татарстан Республикасы дәүләт урман инспекторы таныклыгы урман фонды җирләрендә федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урманнарны саклауны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затка түбәндәгеләр нигезендә бирелә:

урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урманнарны саклауны, федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затларның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган исемлекләре;

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренең – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы урманчылыкларның федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазифаи затларының Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән раслана торган исемлеге.»;

3.2 пунктта «урманнарда федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманнарны саклауны), федераль дәүләт янгын күзәтчелеген» сүзләрен «урман фонды җирләрендә федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урманнарны саклауны» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин